# ГРАЖДАННАР ҖЫЕНЫ КАРАРЫ

**Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районы Косяково авылы Норлат авыл җирлеге торак пунктында гражданнар җыены нәтиҗәләре турында**

**11 апрель 2024ел** **№ 15**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә гражданнар җыены «11» апрель 2024ел 11 сәгатъ 30 минутта (пәнҗешәмбе) гражданнарның җыены нәтиҗәсе белән протокол төзелде тубәндәге сорау буенча:

«Сез Зеленодольск муниципаль районы Норлат авыл җирлеге торак пунктында Косяково авылында гражданнар җыены нәтиҗәләре турында 2023 елның 18 ноябрендәге 2 номерлы карарның 2 пунктын яңа редакциядә бәян итеп карарның 2 пунктына үзгәрешләр кертүгә ризамы (алга таба-Карар):

1) торак пункт чикләрендә җирле әһәмияттәге гомуми файдаланудагы автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, тоту (шул исәптән бу максатлар өчен инерт, төзелеш материаллары һәм кече архитектура формалары сатып алу, смета документациясен әзерләү, төзелеш контролен гамәлгә ашыру).

2) Косяково авылының Үзәк урамы буенча җирле әһәмияттәге гомуми файдаланудагы автомобиль юллары составына кермәгән җәяүлеләр күперләрен һәм юл үткәргечләрен, җәяүлеләр өчен җир өстендәге юлларны ремонтлау (шул исәптән: инерт материаллар сатып алу, смета документларын әзерләү, төзелеш контролен гамәлгә ашыру, килешү буенча эшләр һәм хезмәтләр өчен түләү).

Гражданнар җыены нәтиҗәләре турында беркетмә нигезендә: Сайлау хокукына ия булган җыен катнашучылары исемлегенә 122 гражданнар җыенында катнашучылар, тавыш бирүдә катнашкан гражданнар җыенында катнашучылар саны 66 кеше кертелгән, бу 54%тәшкил итә.

Тавыш бирү нәтиҗәләре буенча гражданнар җыенында катнашучыларның тавышлары түбәндәгечә бүленгән:

«РИЗА» позициясе өчен гражданнар җыенында катнашучылар 66 кеше тавыш бирде; «КАРШЫ» позициясе өчен 0 җыенда катнашучылар тавыш бирде.

Бу нигездә, гражданнар җыены карар итте:

1. Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районы Норлат авыл җирлеге Косяково авылы торак пунктында гражданнар җыены узган дип танырга, гражданнар җыены нәтиҗәләре гамәлдә дип танырга.

2. «Зеленодольск муниципаль районы Норлат авыл җирлеге торак пунктында гражданнар җыены нәтиҗәләре турында 2023 елның 18 ноябрендәге 2 номерлы карарның 2 пунктын яңа редакциядә бәян итеп карарның 2 пунктына үзгәрешләр кертергә сораулар буенча:

«Сез Зеленодольск муниципаль районы Норлат авыл җирлеге торак пунктында Косяково авылында гражданнар җыены нәтиҗәләре турында 2023 елның 18

ноябрендәге 2 номерлы карарның 2 пунктын яңа редакциядә бәян итеп карарның 2 пунктына үзгәрешләр кертүгә ризамы (алга таба-Карар):

«2. Алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлтергә:

1) торак пункт чикләрендә җирле әһәмияттәге гомуми файдаланудагы автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, тоту (шул исәптән бу максатлар өчен инерт, төзелеш материаллары һәм кече архитектура формалары сатып алу, смета документациясен әзерләү, төзелеш контролен гамәлгә ашыру).

2) Косяково авылының Үзәк урамы буенча җирле әһәмияттәге гомуми файдаланудагы автомобиль юллары составына кермәгән җәяүлеләр күперләрен һәм юл үткәргечләрен, җәяүлеләр өчен җир өстендәге юлларны ремонтлау (шул исәптән: инерт материаллар сатып алу, смета документларын әзерләү, төзелеш контролен гамәлгә ашыру, килешү буенча эшләр һәм хезмәтләр өчен түләү).

5. Әлеге карарны Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталында (http://pravo.tatarstan.ru) Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре порталы составында Зеленодольск муниципаль районының мәгълүмати сайтында (http://zelenodolsk.tatarstan.ru шулай ук Татарстан Республикасы, Зеленодольск муниципаль районы, Норлат авылы, Гагарин урамы, 46 нчы йорт (җирлек администрациясе бинасы), Норлат авылы, ур. М. Фәйзуллина, 17 нче йорт (ЦКС «Заволжье» бинасы) мәгълүмат стендларында бастырып чыгарырга.

6. Әлеге карарны Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары Регистрына кертү өчен җибәрергә.

Гражданнар җыенында рәислек итүче И.М.Саттаров